ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КОРМАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ЖИТӘКЧЕСЕ

423733, Иске Кормаш авылы,
Үзәк ур.,29 нчы йорт. Тел.3-44-56

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ СТАРОКУРМАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423733, село Старое Курмашево,
ул. Центральная,дом 29, Тел. 3-44-56

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

от «26» февраль 2025 ел № 7

**Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Иске Кормаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында» 16.03.2020 ел, № 11 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 15.06.2022 № 1081 карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Иске Кормаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 16.03.2020 ел, № 11 карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Иске Кормаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлегенең 3.6 пунктында:

- А) икенче абзацта", дәүләт (муниципаль) программаларының структур элементларына" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"ташламалар алу хокукыннан файдаланган түләүчеләр санының һәм ташламалар куллану өчен потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының яисә түләүчеләрнең гомуми санының 5 еллык чорга нисбәте белән характерлана торган бирелгән ташламаларны түләүчеләрнең ихтыяҗы.";

в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Салым чыгымнары кураторы тарафыннан бирелгән ташламаларның түләүчеләр тарафыннан таләп ителүен бәяләүне уздыру максатларында әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән ташлама кирәк дип танылa торган чагыштырманың минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин.".

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 3.9_1 пункт өстәргә:

3.9_1. Кирәк булганда салым чыгымы кураторы тарафыннан Россия Федера-

циясе субъекты (муниципаль берәмлек)салым чыгымының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүнең өстәмә критерийлары билгеләнергә мөмкин

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 3.10_1 пункты өстәргә:

3.10_1. Россия Федерациясе субъектларының (муниципаль берәмлекләрнең) салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләүне Россия Федерациясе субъектларының (муниципаль берәмлекләрнең) техник салым чыгымнарына карата үткәрмәскә рөхсәт ителә.

3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтындагы "Авыл җирлекләре" бүлегендә түбәндәге адрес буенча http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Д.Р.Вәлиева